ГЛАВА СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2020 г. Болгар № 41

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
районы җирле үзидарә органнарының
муниципаль хезмәткәрләре саны һәм
аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы
чыгымнар турында квартал саен белешмәләр
бастырып чыгару тәртибен раслау хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны турында квартал саен белешмәләрне һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнарны бастырып чыгару тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетына йөкләргә.

Спас муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе Ф.В. Мөхәммәтов

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
районы башлыгы карарына 1 нче кушымта
2020 елның 11 июненнән № 41

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләр бастырып чыгару тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен бирелә торган белешмәләрне (алга таба - Тәртип) бастырып чыгару тәртибе "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Тәртип Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен бирелә торган белешмәләрне (алга таба - белешмәләр) тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели.

## II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында белешмәләрне тапшыру һәм аларның составы

2.1. Белешмәләр квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең уртача исемлек саны турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына түләүләр буенча чыгымнарны гамәлгә ашыруга факттa җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре күләме (акчалата тәэмин итү) хакында, хезмәт хакына түләүләрне исәпкә алмыйча, квартал саен бирелә торган мәгълүматны (арта барган нәтиҗә белән) чагылдыра.

2.2. Белешмәләр хисап чорыннан соң килә торган айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге рәвеш буенча тапшырыла.

2.3 Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - башкарма комитет) әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча мәгълүмат формалаштыра.

## III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе

3.1. Башкарма комитет хисап чорыннан соң килә торган айның соңгы көненнән дә соңга калмыйча мәгълүматларны раслау турында башкарма комитет карары проектын әзерли.

3.2 Башкарма комитет карары белән расланган белешмәләр хисаптан соң килүче икенче айның соңгы санына кадәр Спас муниципаль районы сайтында басылып чыгарга тиеш (http://www.spasskiy.tatarstan.ru).

Спас муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең
саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы
чыгымнар турында квартал саен бирелә торган
белешмәләрне бастырып чыгару тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында белешмәләр

20___ елның ________ хисап чоры (беренче квартал, артыеллык, тугыз ай, ел)

| Хезмәткәрләр категориясе | Хисап чорында хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны, кеше | Хисап чорында хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар, мең сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының ______ авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |